

Ләмберә авылында яшәvче Камиль Нәсрулла улы Мензуллин vзенен 93 яшьлек юбилеен кондәлек хезмәтләрендә каршы алган.
Бу вакыйгага кадәр язма героебыз vз мотоблогында бакча туфрагын vзе сукалый. Ә сентябрьдә 50дән артык чиләк бәрәнге казыган, аннары аларны базга тошергән, сорvлекләрне бәрәнгенен коры боткаларыннан һәм тамырларыннан чистарткан. Бакчада тәртип урнаштырган: хәзер ул жимеш агачларын кышка әзерли. Камиль Насрулла улы хатыны Махинур Үмәр кызы белән Ләмберә авылында vз йортында яши. Ләмберәдә туган 27 яшьлек Нәсрулла Татар Свербеевкасында туып vскән 25 яшьлек Махинурга ойләнеп яши башлыйлар һәм бvген 66 ел дәверендә бер-берсен хормәт итеп, матур һәм тату яшиләр. Торле тормыш ситуацияләрендәге авырлыкларны жинеп чыгарга мәхәббәт һәм vзара анлашу гына булыша. Бvген аларны кызы Галия һәм улы Шамильнен дvрт балалары һәм аларнын кыз оныклары әти-әниләрен, әби-бабайларын бик яраталар; кунакка гына тvгел, ә ойдә дә ярдәм итәргә дә тырышалар.
Яхшы, иркен агач йорты. Камиль Нәсрулла улы аны vз куллары белән һәм vз проекты буенча тозегән. Йорт ата-анасы йорты урынында тора. Ә ул яшьлеген әти-әнисе, абыйлары һәм апалары белән саман йортында 10 кешеле гаиләдә vткәрә.
Камиль Нәсрулла улы Мензуллин Боек Ватан сугышы чоры баласы, һәм анын нәрсә икәнен ишетеп кенә белми. Ана һәм абый-апаларына сугыш алдыннан һәм аннан сон һәрторле авырлыкларны тулысынча татырга туры килә: vгезләр белән жир соргәннәр, ачлык кичергәннәр, басулардан чыршы жыеп йоргәннәр... Олкәннәргә ярдәм йозеннән язма героебыз кечкенәдән колхозда эшләгән. 1951 елда Камиль Мензуллинны армиягә алалар. Ике елга якын ул Украина милләтчеләре, гадирәк әйткәндә, бандеровчылар оешмасы челтәрен юк итv буенча хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. Һәм менә бервакыт могжиза була: Конбатыш Украинада Нәсрулла улы Камиль туган абыйсы Бясыр белән очраша. Аны да армиягә алганнар икән. Шуннан кардәшләр бер хәрби подразделениедә хезмәт итә башлаганнар: бер танкта, бер экипажда. Камиль механик-водитель, ә Бясыр – наводчик дәрәжәсендә. Бергә хезмәт иткәндә аларны беркайчан да аермаганнар һәм заданиеләргә дә бергә жибәргәннәр. Намуслы, кыю хезмәт иткәннәр алар. Хәтта кардәшләрдән башка хәрби хезмәткәрләр vрнәк алганнар – сафта да, физик әзерлектә дә. Яшь солдатлар, жәрәхәтләр булмасын очен, хезмәттәшләреннән хәтта аякларына портянканы дорес бәйләргә ойрәнгәннәр.
Армиядә хезмәт иткәннән сон, Камиль Мензуллин әти-әнисе йортына кайта. Шоферлыкка ойрәнә, аннары 30 елдан артык туган Мордовиясендә шофер булып эшли. Башта Саранскта Урал һәм ЗИЛ йок машиналарында эшли, аннары чирек гасыр КПССнын Ләмберә район комитетында жинел машиналар йортvчесе булып хезмәт итә.
- Район комитетында машина йортvчеләрнен эш графигы торле иде: сигез сәгатьлек тә, коненә 13 сәгать тә, - дип искә ала К.Н.Мензуллин. – Егерме биш ел буе коне-тоне эшләдем. Дорес, ел саен ялда була идек. Бу яктан барысы да тиешенчә булды. Без ял гына тvгел, дәвалау да ала идек, хәтта дингезгә дә, ял йортларына да хатыным белән бергә булдык. Ләмберәдә торле секретарьлар белән эшләргә туры килде: катгый һәм

бик vк тvгел дə. Лəкин барысы да мина анлау һəм хормəт белəн карадылар. Мин бит Саранскидан Березин, Астайкин, Пиксайкин, Гаваевны – “Зур начальникларны” да йорткəн идем…
Туган авылында Камиль Нəсрулла улы, легендар кеше дип əйтергə була. Кvз алдыгызга китерегез, ул хəзер дə машина йортə ала. Лəкин ул утырмый, чонки vзенен шəхси УАЗигын кvптəн саткан: прицеплы мотоблокта йори. Нигездə, район vзəгендə яшəvче кызы Галия йортына кадəр. Ул ана vзеннəн нəрсəдер илтеп, аннан нəрсəдер алып кайта. Ə жəй коне Лопатино авылы ягындагы урманга каен вениклары жыярга бара. Мəсəлəн, быел 50лəп мунча венигы алып кайткан. Ботен гаилəгə житəрлек, ди. Камиль Нəсрулла улы аяк авырулары һəм артериаль басымнын вакыт-вакыт кvтəрелve турында зарланса да, барыбер хəрəкəт итəргə тырыша. Телевизордан “Яналыклар” тынлый, урамга чыга, бакчага тошə, кибеткə барып кайта. Камиль абый тормышы белəн канəгать; анын һəм хатынынын пенсиялəре имин яшəр очен житəрлек дип саный.

**Н.ХЭЛИЛ** *«Призыв» газетасы корреспонденты Николай Степанов материалы буенча эзерлэде*